ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**10.03.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 505**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 27 ноябрендәге 2281 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәт күрсәтүләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында

2008 елның 19 декабрендәге «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәт күрсәтүләреннән бертигез файдалануны тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 27 ноябрендәге 2281 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәт күрсәтүләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия составын, әлеге карардагы кушымтада бирелгәнчә, яңа редакциядә, расларга.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 декабрендәге «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 27 ноябрендәге 2281 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәт күрсәтүләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия

составына үзгәрешләр ккертү турында» 3380 номерлы карарының 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
кушымта
10.03.2022 ел №505

**Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәт күрсәтүләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия составы**

| № т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Ганиев Ильяс Рәсим улы | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе-**Комиссия рәисе** |
| **Комиссия әгъзалары:** | | |
| 2 | Хәбибуллин Зөлфәт Флүн улы | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| 3 | Хәббихуҗин Ирек Хикмәтулла улы | «Төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ җитәкчесе урынбасары-**комиссия секретаре** |
| 4 | Бауэр Анастасия Сергеевна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары вазыйфаларын башкаручы; Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм үсеш бүлеге начальнигы |
| 5 | Содомова Юлия Александровна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге начальнигы |
| 6 | Ламбина Татьяна Михайловна | «ЗМР финанс-бюджет палатасы» МУ җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| 7 | Кадырова Светлана Викторовна | «Зеленодольск муниципаль районының контроль-санау палатасы» МУ рәисе (килешү буенча) |